# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 16 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Каташ-Каран авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1)Каташ-Каран торак пунктындагы зират территориясендә үлән чабу өчен триммерлар сатып алу;

2) Каташ-Каран торак пунктындагы мәктәп территориясе янында төзелеш материаллары сатып алу һәм киртә кую (килешү буенча эшләрне түләү);

3) бадминтон, волейбол һәм теннис өчен спорт кирәк-яраклары сатып алу.

4) Каташ Каран авылындагы су алу манарасына алып баручы юлны ремонтлау

5) Каташ Каран авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләрне түләү).

6) Каташ-Каран торак пунктындагы урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру);

7) Каташ-Каран авылында бәйрәмнәр һәм спорт чаралары уздыру өчен бүләкләр сатып алу;

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева